ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423190, с. Новошешминск, ул. Ленина, 37 «А»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ
423190, Яна Чишмә авылы, Ленин урамы, 37 "А"

тел.факс.: (8-84348) 2-25-47, тел.факс: (8-84348) 2-27-67, Pizo.Nsm@tatar.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ — БОЕРЫК

2023 елның «01» февраль — № 77

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Торак фондының үзләре биләгән торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 31 октябрендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Торак фондының үзләре биләгән торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хокүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерык бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Торак фондының үзләре биләгән торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 31 октябрендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Торак фондының үзләре биләгән торак урыннарын гражданнар милкенә тапшыру (торак фондын хосусыйлаштыру) буенча

муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пункттагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросныц формаль-логик тикшерүе мөрәҗәгать итүченең электрон формадагы запросның һәр кырын тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан запросның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе турында электрон формада хәбәр ителә».

1.2. 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бирергә:

Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлек гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүнең, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү вариантларын үз эченә алырга тиеш.

1.3. 2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге әлеге Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан бирелә.

1.4. 2.5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесне таныклый торган башка документны Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарда, муниципаль

хезмәтләрне күрсәтүче органнарда, мәгълүмати технологияләрне кулланып күпфункцияле үзәкләрдә «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 14_1 статьясындагы 18 өлешендә каралган мәгълүмати технологияләрне кулланып, идентификацияләү һәм аутентификацияләү юлы белән шәхси кабул итү барышында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү очраклары һәм тәртибе әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә алдан (актив) режимда административ регламент белән билгеләнә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының
Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Н. В. Попкова